| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 17.11.2025 г. | № 6 |

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы белән, Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 15 августындагы 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, иҗтимагый берләшмәләрне оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 елларның план чорына гавами тыңлаулар билгеләргә (алга таба - җирлек бюджеты проекты).
2. Авыл җирлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы - Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты.
3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 10 декабрендә 14.00 сәгатьтә;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү урыны - Куакбаш ав., К. Маркс ур., 15 йорт., мәдәният йорты;

3.3. җирлек бюджеты проекты буенча, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, авторның яшәү урыны адресын күрсәтеп, Куакбаш ав., К. Маркс ур., 15 йорт., мәдәният йорты адресы буенча, эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала;

3.4. Бюджет проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү чоры - 2025 елның 21 ноябреннән 2025 елның 08 декабренә кадәр;

3.5. Авыл җирлеге бюджеты проектын халыкны таныштыру өчен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы Лениногорск районы Керкәле ав., Совет ур., 95 й.

4. Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына:

4.1. Әлеге карар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар оештырырга һәм уздырырга;

4.2. Гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) җирлек бюджеты проектын тапшырырга;

4.3. 2025 елның 12 декабренә кадәр җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

5. Җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрне Куакбаш авылы-К. Маркс ур., 15 йорт, Сходнево - Чертанлы авылы - Азатлык ур., 5Б йорт, Чүте авылы-Тынычлык ур., 8а йорт, авыл клубы бинасы. буенча урнашкан мәгълүмат стендларына 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Куакбаш авылы-К. Маркс ур., 15 йорт, Сходнево - Чертанлы авылы - Азатлык ур., 5Б йорт, Чүте авылы-Тынычлык ур., 8а йорт, авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова